**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы**
**Түбән Табын авыл җирлегенә керүче Тугаш авылы**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№ 2** **07.12.2019 ел**

***Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының***
***Түбән Табын авыл җирлеге составына керүче***
***Тугаш торак пунктына 2020 нче елда гражданнарның***
***үзара салымын кертү турында***

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге Тугаш торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Тугаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 нче елда, I группадагы инвалидлардан тыш, 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:
- Җәйге чорда юллларны карау
- Кышкы чорда юлларны карау, чистарту
- Урам утларын кару һәм ремонтлау
- Юлларны карау, ремонтлау
- Иске агачларны кисү
- Территорияне чүп үләннәреннән чистарту
- Янгынга каршы чаралар
- Җирлектә бәйрәм чараларын оештыру, уздыру, бүләкләр алу
- Җирлектәге һәйкәлләрне ремонтлау
- Зиратны әйләндерү
- Тукталышны ремонтлау
- Авыл башына агачлар утырту

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда, Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы, Югары Табын авылы, Тукай урамы, 19б йорт; Тугаш авылы, Вахитов урамы, 10а йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

*Гражданнар җыенында рәислек итүче,*
*Түбән Табын авыл җирлеге башлыгы* *Р.Ш. Кыяметдинов*